Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение
«Детский сад №2«Белочка» г. Нурлат Республики Татарстан»

ПРИНЯТО
на заседании
педагогического совета
МБДОУ «Детский сад №2 «Белочка»
протокол № __1__
от« __31__ » августа 2020 года

УТВЕРЖДАЮ
Заведующий
МБДОУ «Детский сад №2 «Белочка»
__________ …. Сагирова
Приказ № __227__
от «__31__» августа_2020 года

Регистрационный №___

# ПРОГРАММА
## дополнительной образовательной услуги
## *«Уйный-уйный өйрәнәбез»*
## для детей 6-7 лет

Срок реализации дополнительной бесплатной
образовательной программы – 1 год

Составила:
Ибрагимова Венера Райнуровна

Нурлат, 2020

## Аңлатма язуы

Бакчадагы тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә бала яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашырга, әйберләрне танып белергә өйрәнә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә-юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә бу дөньяда яшәргә, үзенең мөгамәләләрен төзергә өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур, әйбәт сөйләшә белүен таләп итә. Сәхнәләштерү уеннарында катнашып, балалар образлар, төсләр, авазлар аша тирә-юнь белән танышалар, ә сораулар балаларны уйларга, анализларга, йомгаклау ясарга мәҗбүр итә. Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда, һәр бала үзенең кичерешләрен, тойгыларын, теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга һәм яшьтән үк өйрәтергә кирәк. Еш кына без киң белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез. Бу проблемалар булмасын өчен, балалар бакчасында театр кую бик зур булышлык күрсәтә. Сәхнәләштерелгән уеннар балаларны шатландыралар. Спектакльләрдә катнашып, балалар тирә-юнь белән, төсләр, авазлар белән танышалар, ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша- яңа сүзләр белән баетыла.

**Программаның максаты:** Театр сәнгате аша балаларның иҗади сәләтләрен, кызыксынуларын үстерү. Уеннар,әкиятләр яратучы шәхес тәрбияләү.

**Программаның төп бурычлары:**

- балаларның иҗади активлыкларын үстерү өчен шартлар тудыру;
- балаларның артистлык күнекмәләрен үстерү;

-акыл үсеше белән сөйләм теленең үсешен үстерү, персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләү, баланың сүз байлыгы арттыру, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләү;

-вак моториканы үстерү;

- хәрәкәт күнекмәләрен формалаштыру;

- курчакларны хәрәкәтләндерергә өйрәтү;

- сәхнәләштерү эшчәнлегенә тотрыклы кызыксынуны үстерү ;

- мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонацияне, тәэсирле чараларны кабатлау теләге тудыру.

- балаларда эстетик, әхлак һәм хезмәт тәрбиясен тормышка ашыру;

- балаларның сәламәтлеген яхшырту;

- сәнгатькә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

**Программаның билгеләнеше:**

Түгәрәк айга ике тапкыр үткәрелә. Түгәрәкне үткәрү вакыты 30 минут.

**«Уйный-уйный өйрәнәбез» түгәрәге программасының актуальлеге:**

Стандартның яңалыгы - белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

«Уйный-уйный өйрәнәбез» **түгәрәге программасы эшчәнлегенең көтелгән нәтиҗәсе:** Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшырды, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары артты. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсте.

- Балаларның милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе.

- Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыру, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арту. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсү.
- Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенү.
- Курчаклар белән иркен хәрәкәт итүгә ирешү.
- Гаилә белән балалар бакчасы, мәктәп арасында җылы мөнәсәбәт тудыру.
-

**«Уйный-уйный өйрәнәбез» түгәрәгенең перспектив планы**

| № п/п | Тема | Максат | Сәг. саны | Үткәрелү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш. Театр турында әңгәмә. | Сәнгатьнең бер төре буларак театр турында балаларның белемнәрен тирәнәйтү. | 1 | |
| 2. | Театр һөнәрләре белән танышу. | Балаларда театр турында күнекмәләр формалаштыру, театр сәнгатенә карата кызыксыну уяту. | 1 | |
| 3. | Сюжетлы-рольле уен «Театрда» | Театрда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру.Төрле рольләрне уйнап карарга кызыксыну уяту. | 1 | |
| 4. | Курчак театры турында сөйләшү. Казан “Әкият” курчак театры, курчак театры төрләре белән танышу (слайдлар карау) | Балаларның курчак театры турындагы белемнәрен киңәйтү. | 1 | |
| 5. | Театр төрләре белән танышу. | Балаларны театрның төрле төрләре белән таныштыру. Театр уеннарына кызыксыну уяту. | 1 | |
| 6. | «Геройны уйнап күрсәт». Уен һәм күнегүләр. | Уеннар аша балаларда төрле геройларны уйнап күрсәтергә теләк уяту. | 1 | |
| 7. | «Өч кыз» әкиятен уку. | Балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтү, күзаллауларын үстерү. | 1 | |
| 8. | «Өч кыз» әкиятен сәхнәләштерү. | Геройларның эмоциональ хәлләрен аңларга өйрәтү. Балаларда үз-үзләренә ышаныч хисләре тәрбияләү. | 1 | |
| 9. | Трафарет ярдәмендә уенчыклар ясау. | Балаларны трафарет ярдәмендә курчаклар ясарга өйрәтү | 1 | |
| 10. | Бармак театры белән танышу. | Балаларны бу театр төре өчен кирәк булган күнекмәләргә өйрәтү. | 1 | |
| 11. | «Йомры икмәк» әкиятен уку.Сөйләм өстендә эш. | Балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү. | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Хайваннарга карата мәхәббәт тәрбияләү. | |
| 12. | «Йомры икмәк» әкиятен сәхнәләштерү. (бармак театры) | Бармак театрын уйнау өчен кирәк булган күнекмәләрне үстерү. Артистлык сыйфатлары тәрбияләү. | 1 |
| 13. | «Рольле диалог» төшенчәсе белән танышу. | Геройлар арасында төрле вакыйгаларда диалог төзи белергә өйрәтү. Бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү. | 1 |
| 14. | Сөйләм техникасы. «Күңелле шигырьләр» | Фразаларны төрле интонацияләр белән әйтергә өйрәтү. | 1 |
| 15. | Г.Тукайның «Бала белән Күбәләк», «Кызыклы шәкерт» шигырьләрен уку. | Балаларның игътибарын, тырышлыгын үстерү. Балаларда бер-берсенә карата җылы мөнәсәбәт тәрбияләү. | 1 |
| 16. | Г.Тукайның «Бала белән Күбәләк», «Кызыклы шәкерт» шигырьләрен сәхнәләштерү. | Геройларны дөрес итеп уйнарга өйрәтү | 1 |
| 17. | Өстәл театры белән танышу. | Балаларны өстәл театры белән таныштыру. Уйнау күнекмәләрен үстерү. | 1 |
| 18. | Өстәл театры өчен уенчыклар ясау. | Өстәл театры уйнар өчен уенчыклар ясарга өйрәтү. | 1 |
| 19. | «Шалкан» әкиятен уку. Сөйләм өстендә эш. | Балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Аларның игътибарын, тырышлыгын үстерү. | 1 |
| 20. | «Шалкан» әкиятен сәхнәләштерү. (Өстәл театры) | Балаларны рольгә кереп уйнарга өйрәтү. Артистлык сыйфатлары тәрбияләү. | 1 |
| 21. | Театр эшчәнлеге төрләре белән танышу. (йомшак уенчык) | Балаларны театр эшчәнлеге төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Уйнау күнекмәләрен үстерү. | 1 |
| 22. | «Тавышны үзгәрт», «Мине аңла».Уен күнекмәләре. | Балаларның хәтерен, фикерләү сәләтләрен, күзәтүчәнлекләрен үстерү. | 1 |
| 23. | Шәүлә театры белән танышу. | Балаларны театрның төрле төрләре белән таныштыруны дәвам итү.аларның иҗади сәләтләрен үстерү. | 1 |
| 24. | «Теремкәй» әкиятен уку. | Балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Аларның игътибарын, тырышлыгын үстерү. | 1 |
| 25. | «Теремкәй» әкиятен сәхнәләштерү.(шәүлә театры) | Балаларны бу театр төре өчен кирәк булган күнекмәләргә өйрәтү. | 1 |
| 26. | Театр эшчәнлеге төрләре белән танышу. (курчак театры) | Балаларны театр эшчәнлеге төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Аларда кызыксыну уяту. | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 27. | Курчаклар белән уйнау. | Балаларны курчаклар белән идарә итәргәи өйрәтү. Театр эшчәнлегенең бу төренә карата мәхәббәт тәрбияләү. | 1 |
| 28. | «Хәйләкәр этәч» әкиятен уку. | Балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Аларның игътибарын, тырышлыгын үстерү. | 1 |
| 29. | «Хәйләкәр этәч» әкиятен сәхнәләштерү.(курчак театры) | Балаларны бу театр төре өчен кирәк булган күнекмәләргә өйрәтү. | 1 |
| 30. | Театр эшчәнлеге төрләре белән танышу. (битлек театры) | Балаларны театр эшчәнлеге төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Битлек театры белән таныштыру. | 1 |
| 31. | «Өч аю» әкиятен уку. Сөйләм өстендә эш. | Балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Аларның игътибарын, тырышлыгын үстерү. | 1 |
| 32. | «Өч аю» әкиятен сәхнәләштерү. (битлек театры) | Артистлык сәләтләрен үстерү. | 1 |
| 33. | Абдулла Алишның «Сертотмас үрдәк» әкиятен уку. Сөйләм өстендә эш. | Балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Аларның игътибарын, тырышлыгын үстерү. | 1 |
| 34. | Абдулла Алишның «Сертотмас үрдәк» әкиятен сәхнәләштерү. | Геройларны дөрес итеп уйнарга өйрәтү | 1 |
| 35. | Абдулла Алишның «Сертотмас үрдәк» әкиятен торкемдә уйнап күрсәтү. | Балаларда театр сәнгатенә карата кызыксыну уяту | 1 |
| 36. | Абдулла Алишның «Сертотмас үрдәк» әкиятен әти-әниләргә уйнап күрсәтү. | Балаларда үз-үзләренә ышаныч хисләре тәрбияләү. | 1 |

**Кулланылган әдәбият исемлеге.**


1. Балалар бакчасы. әти-әниләр һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен уку китабы. Казан “Раннур” нәшрияты, 2003.

2. Гөлбакча. Балалар өчен хрестоматия. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1990.

3. Исәнбәт Н. Балалар фольклоры. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1994.

4. Татарча мульфильмнар, Әкиятләр. ИКТ.

5.Закирова К.В.Балачак аланы:балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия.- Казан:РИЦ, 2011.-560б.

6.Закирова К.В.Иң матур сүз:Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия.-Казан:Мәгариф,2000.-335б.

7.Ягъфаров Р. Татар балалар фольклоры.-Казан: «Раннур»нәшрияты, 1999.-325б.

8.Зарипова Ф.Я. Могҗизалы мәктәп сәхнәсе:Балалар бакчасы тәрбиячеләре, сыйныф җитәкчеләренә ярдәмлек.-Казан:Мәгариф, 2003.-255б.

9.Закирова К.В.Әхлак нигезе – матур гадәт (Гаиләдә һәм балалар бакчаларында әдәп-әхлак тәрбияләү):Методик кулланма.-Казан:Мәгариф, 2004.-383б.

10.Закирова К.В.Балачак-уйнап-көлеп үсәр чак: балалар бакчасында уеннар:балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма.-Казан:РИЦ, 2012.-192б.

11.Л.Х.Дәүләтшина.Бармакларны уйнатабыз-сөйләм телен үстерәбез.-Казан:РИЦ «Школа», 2009.-36б.